СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.05.2023 с. Сарманово № 142

Сарман муниципаль районында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында «Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 26 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Советының 2013 елның 11 мартындагы 105 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 нче бүлекнең 3 нче пунктын түбәндәге эчтәлектәге пунктчалар белән тулыландырырга:

«10) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт үткән чорда;

11) ирекле формированиедә булу турында контракт төзегән гражданнар (Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм турында), Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу шарты белән - ирекле формированиедә булу турында контракт гамәлдә булган чорда (Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм турында);

12) 10, 11 нче пунктларда күрсәтелгән гражданнарның гаилә әгъзалары:

а) ата-аналар (уллыкка алучылар);

б) ир (хатын)

в) балигъ булмаган балалар, шул исәптән уллыкка алынганнар, тәрбиягә алынганнар һәм опека (попечительлек) астында булганнар;

г) 18 яшькә кадәр инвалид булган 18 яшьтән өлкәнрәк балалар;

д) көндезге уку формасы буенча белем бирү оешмаларында белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар;

е) алар карамагында булган кешеләр.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район

Советы рәисе Ф. М. Хөснуллин